ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында” Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында” 2012 елның 14 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 3 өлешенең 3 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш) “Хәрби хезмәткәрләр, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарының гади һәм башлык составы затлары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының хезмәткәрләре гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында” 1998 елның 28 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон” сүзләрен “Хәрби хезмәткәрләр, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең гади һәм башлык составы затлары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының хезмәткәрләре, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең хезмәткәрләре гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында” 1998 елның 28 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 3 октябре
№ 79-ТРЗ